ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12.11.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2157**

2021 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансланган кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 елның 06 октябрендәге 908 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карарына, 2015 елның 29 декабрендәге «Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 388-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китереп һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 181-ФЗ номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елның 11 гыйнварыннан, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучыларга, һәр уку көненә 53 сум 41 тиен күләмендә, бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүне оештырырга.

2. 2021 елның 11 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмаларында

укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү өчен, һәр уку көненә 8 сум күләмендә билгеләргә.

3. 2021 елның 11 гыйнварыннан, Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче һәр укучыга һәр уку көненә 61 сум 31 тиен күләмендә, түбәндәге категорияләргә, билгеләргә:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләдәге укучыларга;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы «Норлат балалар йорты» ятим балалар һәм әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт автоном учреждениесендәге тәрбияләнүчеләргә;

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раифа урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы Раифа Богородицкий ирләр монастыреның балалар корпусында тәрбияләнүчеләргә.

4. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә, гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны, 2021 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә, гамәлгә ашырырга.

5. Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (ЕГИСО) операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (ЕГИСО) йөкләү өчен, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев